КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2023 ел, 6 март г.Казань № 214

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының Биология ресурслары буенча дәүләт комитеты мәсьәләләре» 2017 ел, 15 декабрь, 996 нчы карарына үзгәреш кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының Биологик ресурслар буенча дәүләт комитеты мәсьәләләре» 2017 ел, 15 декабрь, 996 нчы карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2018 ел, 26 февраль, 110 нчы; 2018 ел, 7 май, 327 нче; 2018 ел, 30 июль, 614 нче; 2018 ел, 29 декабрь, 1288 нче; 2019 ел, 23 апрель, 329 нчы; 2019 ел, 18 декабрь, 1165 нче; 2020 ел, 11 февраль, 87 нче; 2020 ел, 15 май, 392 нче; 2020 ел, 8 август, 666 нчы; 2021 ел, 17 июнь, 467 нче; 2021 ел, 11 август, 700 нче; 2021 ел, 6 сентябрь, 817 нче; 2021 ел, 27 ноябрь, 1140 нчы; 2021 ел, 9 декабрь, 1209 нчы; 2022 ел, 7 март, 202 нче; 2022 ел, 17 март, 244 нче; 2022 ел, 29 апрель, 402 нче; 2022 ел, 22 сентябрь, 1029 нчы, 2022 ел, 11 ноябрь, 119 нчы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып), 2 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итеп, үзгәреш кертергә:

«2. Татарстан Республикасының Биология ресурслары буенча дәүләт комитеты хезмәткәрләренең иң чик санын вазыйфаи окладлары буенча хезмәт өчен түләүнең бер айлык фонды 2 854,1 мең сум булган 159 берәмлек күләмендә түбәндәге очракларда билгеләргә:

40 берәмлеге – вазыйфаи окладлары буенча хезмәт өчен түләүнең 883,9 мең сумлык айлык фонды белән үзәк аппараты хезмәткәрләре, шулардан:

18 берәмлеге – федераль бюджеттан бирелә торган субвенцияләр исәбеннән финанслана торган вазыйфаи окладлар буенча хезмәт өчен түләүнең 327,9 мең сумлык айлык фонды белән;

22 берәмлеге – Татарстан Республикасы бюджетыннан финанслана торган вазыйфаи окладлар буенча хезмәт өчен түләүнең 556,0 мең сумлык айлык фонды белән;

119 берәмлеге – вазыйфаи окладлары буенча хезмәт өчен түләүнең 1 970,2 мең сумлык айлык фонды белән территориаль бүлекчәләр хезмәткәрләре;

18 берәмлеге – федераль бюджеттан бирелә торган субвенцияләр исәбеннән финанслана торган вазыйфаи окладлар буенча хезмәт өчен түләүнең 378,9 мең сумлык айлык фонды белән;

101 берәмлек - Татарстан Республикасы бюджетыннан финанслана торган вазыйфаи окладлары буенча айлык хезмәт хакы фонды 1 591,3 мең сум.».

2. Бу карарның гамәле 2023 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла дип билгеләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры
вазыйфаларын башкаручы Р.К.Нигъмәтуллин